**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2015 Балык Бистәсе штп. № 359пи

Муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла һәм Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең ведомство исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 статьясындагы 3.1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлеген формалаштыру һәм алып бару, федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт хезмәтләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау, һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган дәүләт (муниципаль) хезмәтләренең һәм эшләрнең ведомство исемлеген формалаштыруга, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләр турында» 2014 елның 26 февралендәге 151 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм хезмәтләрнең ведомство исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау турында»28.12.2015 № 359пи карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль хезмәтләрнең һәм муниципаль учреждениеләр төрләре буенча эшләрнең ведомство исемлеген расларга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль учреждениеләр, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә торган һәм Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль хезмәтләр исемлеге турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 29 декабрендәге 445пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин